# ЧИШМӘ БАШЫ




Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «МӨНДЕШ БАЛАЛАР БАКЧАСЫ» МБМББУ, декабрь, 2025 ел № 12

***Ата-аналар һәм балалар өчен мәгълүмати-танып белү газетасы***

### *Газетаның сәхифәләре:*

1. *Яңа ел бизәкләре*
2. *«Балалар бакчасында Каюм Насыйриның педагогик мирасын куллану»*
3. *Сәламәт тәндә - сәламәт акыл.*
4. *«Көмеш тавыш» - талантлар бәйгесе*

**Баш мөхәррир:**
**балалар бакчасы мөдире**
**Мостафина Р.Г.**
**Мөхәррир урынбасарлары:**
**музыка җитәкчесе Хөсәенова Г.Ф.**
**тәрбиячеләр: Хөсәенова Р.Р.,**
**Җәләлиева А.Г., Шәкүрова Р.С.,**
**Хөсәенова В.В.**

Тиздән елның иң сихри, могҗизаларга бай бәйрәме – Яңа ел җитә. Бу бәйрәмне балалар аеруча көтеп алалар. Шул уңайдан, декабрь башында ук бакчабызның бүлмәләрен бизәп куйдык. Тәрәзәләргә матур наклейкалар ябыштырдык, гирляндалар элдек. Бакчабыз тагын да ямьләнеп китте.


Бакчабыз территориясен фанердан ясалган сыннар белән бизәдек, агачларга гирляндалар элдек. Алар әллә кайдан балкып, авылыбыз урамына ямь биреп торалар.

Ә иң мавыктыргычы бакчабызның коридорына фотозона ясадык. Анда хәтта Яңа елның символы – Ат сыны да үз урынын алды. Фотозонабыз бик зәвыклы, матур килеп чыкты. Район күләмендә үткәрелүче “Иң әкияти фотозона” бәйгесендә дә катнашабыз. Уңышлар безгә!!!







***«Балалар бакчасында Каюм Насыйриның педагогик мирасын куллану»***





ДИПЛОМ

«Каюм бабай дәресе» бәйгесенең

«Каюм Насыйри һәм тәрбия» номинациясендә

I урын яулаган

Шәкурова Рокыя Сәүбән кызы

бүләкләнә

И. Г. Һадиуллин

А. С. Салимгәрәев

И. Ф. Фазуллин



ДИПЛОМ

Татарстан Республикасы мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләреннең

татар теле тәрбиячеләре арасында үткәрелүче

“Белем һәм тәрбия бирүдә Каюм Насыйри хезмәтләре”

республикакүләм бәйгесендә

III урын

белән

Җәләлиева Айгөл Госман кызы

“Каюм Насыйри- галим” номинациясе

бүләкләнә

И.Ә. Хамитов

Г.Ф. Гарипова

Л.М.Гыймадиева

Биектау, 2025 ел

Күренекле татар мәгърифәтчесе, тел галиме, язучы, тарихчы, тәрҗемәче Каюм Насыйри тууга 200 ел булу уңаеннан «Ватаным Татарстан» газетасы укытучылар һәм тәрбиячеләр арасында уздырган «Каюм бабай дәресләре» бәйгесенең “Каюм Насыйри һәм тәрбия” номинациясендә тәрбияче Шәкурова Рокыя Сәүбән кызы 1 урын яулады.

Биектау муниципаль районы “Ямаширмә “Йолдыз” балалар бакчасы оештырган «Белем һәм тәрбия бирүдә Каюм Насыйри хезмәтләре» республикакүләм бәйгесендә  катнашып, тәрбияче Җәләлиева Айгөл Госман кызы «Каюм Насыйри – галим» номинациясендә 3 урынга лаек булды.

Котлыйбыз!

**Алда да уңышлар телибез.**

**Кыш көне балалар бакчасында ачык һавада йөрү, күңел ачу сәламәтләнүнең иң яхшы ысулы.**

Саф һавада уйнау балаларның салкын тию авыруларына чыдамлыгын арттырырга ярдәм итә. Кышкы саф һавада балаларның организмы ныгый, иммунитеты яхшыра.

Безнең балалар саф һавада уйнарга бик яраталар. Тауда шуалар, кар бабай ясыйлар, кечкенә көрәкләр белән участокны кардан чистартырга булышалар.

Шулай ук без балалар белән кошларны, агачларны, күкне күзәтергә яратабыз.





**Шушы көннәрдә безнең балалар бакчасына районкүләм дәрәҗәдә уздырылучы «Көмеш тавыш» исемле талантлы балаларның җыр бәйгесендә катнашырга насыйп булды.**

10-нчы балалар бакчасы иртәдән сихри музыка тавышына күмелде.

Барлыгы 23 йолдызчык үзләрен җыр-моңга талантлы булуларын жюри каршында күрсәттеләр. Катнашучы балаларның тәрбиячеләре, әти-әниләре һәр балага көч биреп, алкышларга күмеп утырдылар. «Көмеш тавыш» - ел да уздырыла торган бәйге генә түгел, ә чын мәгънәсендә музыка дөньясы белән танышу, яңа мөмкинлекләр тудыру, тәҗрибә туплау чарасы.

Барлык балалар да бу бәйгедә көч сынашсалар да, алар барысы да җиңүче!

Безнең балалар бакчасыннан Хөсәенов Әнвәрнең чыгышын тамашачы аеруча алкышларга күмде. Шуңа да ул лаеклы 3-нче урын яулады. Афәрин!





